# *“Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда ритмны тоемлау хисен үстерү”*

**Максат: -** ритмны тою, сизү хисләрен булдыру. Төрле уеннар, күнегүләр аша максатка ирешү.

**Бурычлар: -** төрле алымнар кулланып мәктәпкәчә яшьтәге балаларда ритмны тоемлау хисен тәрбияләү;

- мастер –классның эчтәлеген ачу, уеннар белән таныштыру;
- балаларда ритмлау хисен булдыруның кирәклеген аңлату.

**Мастер –классның әһәмияте:** педагогларның профессиональ белемнәрен күтәрү. Төрле алымнар кулланып, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ритмны тоемлау хисләрен үстерүдә ярдәм итү.

**Мастер-класста катнашучылар:** масстер-класс музыка җитәкчеләренә, тәрбиячеләргә, әти-әниләргә каралган.

**Мастер-классның структурасы:** - кереш өлеш – “мәктәпкәчә яшьтәге балаларда ритмлау хисләрен булдыру”

- практик өлеш – төрле алымнар кулланып, ритмны үстерү өстендә күнекмәләр белән таныштыру.

**Кереш өлеш.**

Кеше төрмышы аерым бер ритмда яши. Көнне – төн, җәйне –кыш алыштыра. Безнең организмда да йөрәк, сулыш алу ритм астында бара.

Нәрсә соң ул музыкаль ритм? Ритм –ул кыска һәм озын авазларның чиратлашуы.

Барлык музыкаль сәләтләргә караганда, баланың ритмны ишетү, тоя белү сәләте күпкә озагырак формалаша. Ритмны үстерү, ритмны ишетергә өйрәтү мөмкин түгел дигән фикерләр дә йөри галимнәр арасында. Ләкин яңа гасыр ысуллары һәм практик гамәлләр аша бу фикерне кире кагалар. Иң мохиме аны үстерү өстедә кечкенәдән үк эшли башлау кирәк. Шуңа күрә дә балалар бакчасыннан ук балаларда ритмны тоемлау хисен үстерү төп максат булып тора. Ритм – музыка шөгыленең барлык өлкәләрендә ә чагылыш таба.

Галимнәр фикере буенча ритмик тәрбияне  күреп, ишетеп кенә түгел, ул хәрәкәттә дә чагылырга тиеш. Ритмны формалаштыруда бөтен тән катнашырга тиеш.

Шуның өчен мин сезгә кечкенә генә вакытка, 5-7 яшьлек балалар булып торуыгызны телим. Һәм минем белән хәрәкәт итеп алырга чакырам. Мин сезгә ритмны үстерү буенча берничә уен тәкъдим итәм.

**Практик өлеш.**

1. Исәнәшү ( Л.Делиба көенә бармаклар бн уен)
2. Таякчыклар белән күнегү.

Безнең атлар йөгерәләр но, но, но!
Безнең атлар ярышалар но, но, но!
Яланда алар уйныйлар хоп, хоп, хоп!
Тояклары ишетелә хоп, хоп, хоп!

3. “Күңелле шомнар” (оркестр)

Максат: - балаларда уйлау, фикерләү, фантазияләрен үстерү;

- ритмны тыңлап, бергә уйнарга өйрәтү.

Бурычлар: - балаларны төрле алымнар белән таныштыру, көнкүреш материаллардан да музыка чыгарып булганын аңлату;

- ритмны ишетү, тою хисләрен булдыру;
- оркестрда уйнау белемнәрен арттыру.

Җиһазлар: - ярма белән савыт, су белән стакан, пакет, пергамент кәгазе.

Бүген мин сезне “Күңелле шомнар” дигән оркестрда уйнарга чакырам. Нинди уен  кораллары шомлы уен коралларына керә безнең?  (кашыклар, барабан, кыңгырау һ.б) шомлы уен коралларына бәреп уйнала торган уен кораллары керә. Калган музыка уен коралларына караганда, шомлы музыкаль уен коралларында балалар тизрәк уйнарга өйрәнәләр. Чөнки аларда уйнау өчен алдан әзерлек кирәкми. Ритмны тойган бала көйгә кушылып шөгыль вакытында ук уйный ала.

Бүген без дә сезнең белән шомлы оркестр оештырабыз. Ләкин безнең оркест гади түгел. Без уен кораллары урынына гади көнкүрештә куллана торган материаллар алабыз (ярма белән савыт, су белән стакан, пакет,

пергамент кәгазе.)Балалар өчен бу бик кызыклы. Бәйрәмнәрдә, күңел ачуларда оркестрны әти-әниләр белән дә үткәрергә була.

Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

“Актаныш авылы гомуми үсеш бирүче 4 нче балалар бакчасы”
муниципаль бюджет мәктәпкәчә  белем бирү учреждениесе

# Мастер - класс

***“Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда ритмны тоемлау хисен үстерү”***

Төзеде: музыка җитәкчесе
Бәдертдинова И.Р.

Актаныш 2018